ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**__2020 елның 23 гыйнвары** **Чистай шәһәре** **№ 26**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 26 декабрендәге
1055 номерлы карары белән расланган,
Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы территориясендә
муниципаль торак контроле өлкәсендә
законнарны үтәүгә тикшерүләр
уздыруның административ
регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай шәһәре прокурорының 2020 елның 14 гыйнварындагы 02-08-02-2020 номерлы протестын үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында»гы 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешенең 4.1 пунктында каралган планлы тикшерүләрне ел саен үткәрү планына кертү өчен нигез өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 декабрендәге 1055 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле өлкәсендә законнарны үтәүгә тикшерүләр уздыруның административ

регламентына үзгәрешләр кертү хакында административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. II бүлек 2.2.п. 1.п.п. “Функцияләрне башкару тәртибенә таләпләр” түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.п.1п.п. - Торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яисә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турында дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган хәбәрнамә нигезендә гамәлгә ашырыла башлаган көннән алып бер ел узгач».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасары Л.Х. Кашаповага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов